Республика Татарстан
СОВЕТ САБИНСКОГО ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422060, Республика Татарстан, Сабинский район, п.г.т. Богатые Сабы, ул. Школьная, 31а
тел. 2-30-32, 2-31-35
Факс 8(84362) 2-32-35

e-mail: sab.sab@tatar.ru

Татарстан Республикасы
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САБА ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы, Байлар Сабасы ш.т.б., Мәктәп урамы, 31а йорт
тел. 2-30-32, 2-31-35
Факс 8(84362) 2-32-35

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«23» сентябрь 2019 ел № 31

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советы Регламентын раслау турында” 11.09.2015 елгы 49нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Саба районы прокуратурасының 10.09.2019 елгы №02-01-20-19 хатына нигезләнеп, “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлеге Уставына туры китереп, Саба шәһәр җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советының 11.09.2015 елгы 49нчы номерлы карары белән расланган Саба шәһәр җирлеге Советы Регламентының 6 нчы бүлеген түбәндәге эчтәлекле 35нче статья белән тулыландырырга:

“Совет депутатлары булып тормаучы затларның утырышларда катнашу тәртибе:

1. Саба шәһәр җирлеге башлыгы, район прокуроры, шулай ук Саба шәһәр җирлеге Уставы, закончалык белән вәкаләтле вазыйфаи затлар, Советның ачык һәм ябык утырышларында катнашырга хокуклы.

2. Советның ачык утырышларында Саба шәһәр җирлегендә яшәүчеләр һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнаша ала.

3. Совет тарафыннан аларның эшчәнлегенә караган сорауларны караганда, башкарма комитет эшчеләре ачык утырышларда катнашырга хокуклы.

4. Әгәр гомуми депутатларның күпчелеге тарафыннан хупланса, Совет җирле үзидарәнең вазыйфаи затларының утырышта катнашуын таләп итәргә хокуклы.

Катнашу турында таләп, утырышка кадәр өч көннән дә соңга калмыйча, Совет утырышына чакырылучы вазыйфаи затка утырышның көне, вакыты, урыны, утырышка куелган сораулар турында Совет рәисе тарафыннан хәбәр ителергә тиеш.

5. Утырышны ачар алдыннан, Совет рәисе Совет депутатлары булып тормаучы, утырышта катнашучы затлар турында игълан итә.

6. Утырышка чакырылган һәм катнашучы затлар Совет эшенә тыкшынырга хокуклы түгел (чыгыш ясарга, белдерү эшләргә, хуплау яки ризасызлык белдерергә)

7. Совет карары нигезендә, чакырылганнарга әлеге Регламент кысаларында чыгыш ясау өчен сүз бирелергә мөмкин.”

8. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/ saba адресы буенча һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырырга.

9. Карар рәсми бастырып чыгарган көннән үз көченә керә.

10. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Саба шәһәр җирлеге башлыгы урынбасары Р.М.Хәсәнов